

Мәктәпкә гомерләрен биргәннәр мәңгегә укытучы булып кала, диләр. Бvген Кочкурово районында бердән-бер татар авылы булган Татар Умызында туып vскән олы стажлы укытучы, искиткеч хатын – кыз Алия Исмаиловна Умярова турында сvзебез.
...Умяровлар гаиләсендә 6 бала vсә. Авыр вакытлар, барлык балалар да исән калмаган. Әтисе - Исмаил Хосәен улы тимер юлда эшләгән. «1941-1945 еллардагы Боек Ватан сугышы елларында хезмәт батырлыгы очен» медале бар. Әнисе хужалык белән шогыльләнгән. Исмаил кызы Алия туган авылы мәктәбенә укырга бара һәм тырыш укучыларнын берсе була. Шуна кvрә 7-еллык мәктәпне тәмамлагач, Ичалки педучилищесына юллама белән жинел генә укырга керә. - Мина бәхет елмайды дип уйлыйм, - дип башлады сvзен Алия Исмаиловна. - Минем мәктәптә бик яхшы укытучыларым бар иде. Болар – биология укытучысы Рәшидә Хәсән кызы Старкова, рус теле һәм әдәбияты укытучысы Адилә Абдулла кызы Ямбаева. Аларга карап, минем дә балаларны укытасым килде: Ичалки педучилищесына укырга керергә киттем. Имтиханнарны унышлы тапшырдым. Тырыштым, яхшы укыдым. Анда методиканы ныклап бирделәр.
Практикада vз мәктәбемдә булдым. Мине vз укытучыларым кабул итте һәм хезмәткә мәхәббәт тәрбияләде. Шунда укытучылык эше минем һонәрем икәнен анладым.
Әти-әнием дә минем очен шатландылар.
Училищедан сон Татар Умызы мәктәбендә башлангыч сыйныфлар укытучысы булып эшкә килә язма героебыз, ә М.Е.Евсевьев исемендәге педагогия институтын сонрак читтән торып тәмамлый. Башлангыч сыйныфлар белән Алия Исмаиловна озак эшләми: мәктәпкә тел белгече кирәк булгач, олкән буынга рус теле һәм рус әдәбиятын укыта. Балачактан ук туган теленә тартылган педагог туган татар теле белән татар әдәбияты предметлары буенча да белемне якташлары балаларына бирә башлый.
Шәхси тормышына килгәндә, авылдашы Фатих егет Биктяковка кияvгә чыга. Оч кыз һәм бер уллары туа. Тырмыш матур гына чәчәк атканда, Алия Исмаил кызына кырык яшь тә тулмаган чагында, ире бакыйлыкка кvчә. Балалар белән ялгыз кала. Гаиләне

туендырырга, мәктәптә эшләvне дәвам итәргә кирәк иде. Ана кvп нәрсәне жинәргә һәм кичерергә туры килә, әмма дуслары, хезмәттәшләре һәм танышлары аны беркайчан да ометсез, сынык язмыш кичергәнен сизмәгәннәр. Ойдә - балалар, хужалык, терлек. Болар барысы да Алия Исмаил кызынын нәфис жилкәсендә була. Ләкин мәктәп бусагасын атлап кергәч, гәvдәсен турайтып, ишек артында мәшәкатьләрен калдыра ул һәм укучыларын рус һәм туган татар телләренен матурлыгын анларга, әдәбиятны белергә ойрәтә. Шулай мәктәптә 30 ел эшли! Тупланган педагогик тәжрибә, методиканы дорес куллану (ул юкка гына укытучы-методист тvгел) укытучыга дәресләрне югары дәрәжәдә vткәрергә момкинлек бирә. Анын дәресләре мәктәп укучылары очен һәрвакыт мавыктыргыч, кызыклы булган. Ул балаларны яхшыны яманнан, затлыны тvбәннән аерырга, тормышнын бәхете һәм мәгънәсе нәрсәдә икәнен анларга, мостәкыйль булырга, vз-vзенә ышанырга ойрәтә. Анын ничә укучысы барлыгын санап та карамаган. Алар бvген барлык тармакларда эшлиләр, дип шаярта укытучы. Хәтерлиләр, котлыйлар, кунакка киләләр…
Халидә Мортаза кызы Манюрова беренче могаллимәсе турында болай ди: «Блаларга булган мәхәббәте, намуслылыгы, принципиальлеге, теләсә кайсы минутта ярдәмгә килергә әзерлеге кебек кvркәм рухи сыйфатлары аерып тора Алия Исмаил кызын. Ул безгә жылылык һәм яктылык бvләк итте, әйләнә-тирә доньянын кабатланмаслыгын ачты. Үз предметлары буенча белем генә тvгел, мәхәббәт һәм игелек, кызыксынучанлык, гаделлелек, vз-vзенә ышаныч дәресләре дә бирде. Без аны бик хормәт итәбез һәм яратабыз».
Мина калса, укытучынын даны - укучыларында, укучыларынын танылуы - теләсә кайсы укытучы очен топ бvләк.
Хезмәт ветераны, укытучы-методист Алия Исмаил кызы Умярованын бvләкләре байтак: РСФСР Мәгариф министрлыгынын ике грамотасы, РМ башлыгы Рәхмәте, Кочкурово районынын, РОНОсынын Мактау грамоталары...
Педагог буларак унышларга ирешкән Алия Исмаил кызынын балалары да лаеклы кешеләр булып vскәннәр. Бvген жиде оныгы, оч оныкчыгы аны шатландырып торалар. Кызы Румия әнисе эшен кабатлаган: М.Е.Евсевьев исемендәге педагогия институтын тәмамлап, балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Әниләре белән әбиләрен онытмыйлар, даими шалтыраталар, кунакка киләләр.

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**